| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ СПАССКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ СПАС МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

№631 23.08 2022 ел

Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы Башкарма комитетының 2022 елның 08 ноябрендәге 667 номерлы карары белән расланган Торак урыны, торак урыны һәм күпфатирлы йортны яшәү өчен яраксыз дип тану буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, район прокурорының 2023 елның 12 маендагы 02-08-01/2023 номерлы протестын карап чыгып, Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы Болгар шәһәр Башкарма комитеты

КАРАР ИТӘ:

1. Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы Башкарма комитетының 2022 елның 08 ноябрендәге 667 номерлы карары белән расланган Торак урыны, торак урыны яшәү өчен яраксыз һәм күпфатирлы йортны авария хәлендәге һәм сүтелергә яки реконструкцияләнергә тиеш дип тану буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертелергә:
- 2.4.1 пунктның 2 абзацы түбәндәге редакциядә бәян ителергә тиеш: «теркәлгән көннән алып 30 календарь көн дәвамында, ә торак урыннарның җыелма исемлеге яки гадәттән тыш хәл нәтиҗәсендә зыян күргән һәм шул ук вакытта объектларның (торак урыннарның) җыелма исемлегенә кертелмәгән торак урынның милекчесе, хокук иясе яки яллаучысының кергән гаризасы датадан 20 календарь көн дәвамында теркәлү һәм карар кабул итә (нәтиҗә рәвешендә), яки бәяләнә торган бинаны өстәмә тикшерү үткәрү турында карар кабул итә.» .
2. Әлеге карарны Спас муниципаль районының рәсми сайтында (http://spasskiy.tatarstan.ru/) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми сайтында (http:pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.
3. Әлеге карарның үтәлешен тикшерүне ТР Спас муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесенең икътисад буенча урынбасары Р. Р. Закировага йөкләргә.

ТР Спас муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе В.А. Осокин